**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибен һәм шартларын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 2005 елның 9 сентябрендәге ПУ-366 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 11 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-695 номерлы, 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-751 номерлы, 2011 елның 14 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-627 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы һәм 2013 елның 12 февралендәге ПУ-108 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәдә:

7 һәм 8 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасында булган вакыты (командировкага җибәрелгән урынга килү датасы һәм аннан китү вакыты) аның тарафыннан хезмәт командировкасыннан кайткач дәүләт органына тапшырыла торган транспортта йөрү документлары (билетлар) буенча билгеләнә.

Транспортта йөрү документлары (билетлар) булмаганда, граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасында булган фактик вакыты аның хезмәт командировкасында булуын раслаучы, федераль дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән исемлектә каралган башка документларга таянып билгеләнә.»;

10 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

16 пунктта «түләнә» сүзен «кайтарыла» сүзенә алмаштырырга, «шулай ук көннәр» сүзләрен «шулай ук көннәр өчен» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр командировкага җибәрелгән граждан хезмәткәре хезмәт көне тәмамланганнан соң, эшкә яллаучы вәкиле яисә ул вәкаләт биргән зат белән килештергәч, командировкага җибәрелгән урында кала икән, торак бинаны наемга алуга тотылган чыгымнар аңа федераль дәүләт органнарында эшләү турында хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләргә, Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлар, федераль дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясендә хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны кайтару өчен Россия Федерациясендә билгеләнгән күләмнәрдә кайтарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $21^1$ пунктны өстәргә:

«$21^1$. Граждан хезмәткәренең командировкага җибәрелү урынына кадәр һәм кире – Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтен даими узу урынына кайту өчен үз шәхси транспортын файдалануы белән бәйле чыгымнарны кайтару Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә башкарыла.»;

22 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Транспортта йөрү документлары (билетлар) яки транспорт оешмаларыннан бирелгән һәм транспортта йөрү документларындагы (билетлардагы) мәгълүматны раслаучы документлар булмаганда, әлеге Нигезләмәнең $21^1$ пунктында күрсәтелгән чыгымнарны каплаудан тыш, транспортта йөргән өчен түләнми.»;

25 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

29 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Граждан хезмәткәрен Бәйсез Дәүләтләр Берлегенә кергән, алар белән хөкүмәтара килешүләр төзелгән һәм шуларга нигезләнеп илгә керү һәм чыгу документларында чик буе органнары тарафыннан дәүләт чиген узу турында билгеләр куелмый торган дәүләтләр территориясенә хезмәт командировкасына җибәргәндә, Россия Федерациясе дәүләт чиген узу датасы транспортта йөрү документлары (билетлар) нигезендә билгеләнә.»;

35 пунктта:

«а» пунктчасында «тиешле рәвештә тутырылган командировка таныклыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) дәүләт органына хезмәт командировкасында булган вакытта башкарылган эше турында үзе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләп торган структур бүлекчә җитәкчесе белән килештерелгән хисап тапшырырга.»

б) 3 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-

министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе,» сүзләрен өстәргә;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президенты идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президенты департаменты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 ел, 25 февраль
№ ПУ-189